РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
КУКМОРСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН
СОВЕТ ЯДЫГЕРЬСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
422124, РТ, Кукморский район,
с. Ядыгерь, ул.Ленина д.28а

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
КУКМАРА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
ЯДЕГӘР АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ
422124, РТ, Кукмара районы,
Ядегәр авылы, Ленин урамы, 28а йорт

тел.: (8 84364) 35-5-88, факс (8 84364) 35-5-88; e-mail:Yad.Kuk@tatar.ru

КАРАР

07 ноябрь 2024 ел №6

«Кукмара муниципаль районы Ядегәр авыл җирлегенең Түбән- Шәмәрдән авылы торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены үткәрүне билгеләү турында»

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы һәм Кукмара муниципаль районы Ядегәр авыл җирлеге Уставының 22 статьясы нигезендә карар бирәм:

1.2024 елның 22 ноябренә 19 сәгать 00 минутка Кукмара муниципаль районы Ядегәр авыл җирлегенең Починок- Шәмәрдән авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының беренче этабын үткәрүне билгеләргә. Гражданнар җыенын Починок- Шәмәрдән авылы, Совет урамы, 35 нче а йорт адресы буенча урнашкан Починок- Шәмәрдән мәчет бинасында үткәрергә.

2.2024 елның 27 ноябренә 19 сәгать 00 минутка Кукмара муниципаль районы Ядегәр авыл җирлегенең Починок- Шәмәрдән авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының икенче этабын үткәрүне билгеләргә. Гражданнар Починок- Шәмәрдән авылы, Совет урамы, 35 нче а йорт адресы буенча урнашкан Починок- Шәмәрдән мәчет бинасында үткәрергә.

3.Гражданнар җыенын үткәрү өчен торак пунктта яшәүчеләрнең исемлеген территориаль билге буенча (урамнар буенча) бүләргә.

4.Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга: :«1 төркем инвалидлар, көндезге уку формасы буенча укучы укучылар һәм студентлар (курсантлар), 18 яшькә кадәрге бала тәрбияләүче ялгыз әниләр, 80 яшькә житкәннәр һәм аннан да өлкәнрәкләр, Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә срокны хәрби хезмәткә чакырылган затлар, Россия Федерациясе

Кораллы Көчләренә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган затлар һәм аларның гаилә әгъзалары, махсус хәрби операциядә катнашучы хәрби хезмәткәрләр һәм аларның гаилә әгъзаларыннан кала Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Ядегәр авыл җирлегенең Починок- Шәмәрдән авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр яшәүчедән 2025 елда үзара салымны 500 сум күләмендә кертергә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен юнәлтүгә сез ризамы:

- торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, тоту (Починок-Шемордан авылындагы юлларны кышкы-җәйге тоту һәм проект-смета документациясен эшләү, килешү буенча түләү);

(Починок-Шемордан авылының Совет урамы буенча вак таш белән капланган юллар төзү һәм ремонтлау проект-смета документациясен эшләү һәм технадзорны гамәлгә ашыру, килешү буенча түләү);

(Починок-Шемордан авылы урамнарына асфальт салу, проект-смета документациясен эшләү, технадзорны гамәлгә ашыру һәм экспертиза үткәрү, килешү буенча түләү);

- тышкы яктырту челтәрләрен, трансформатор һәм башка подстанцияләрне һәм алар астындагы мәйданчыкларны, бүлү пунктларын һәм электр элемтәләрен тәэмин итү һәм электр энергиясен тапшыруны гамәлгә ашыру өчен билгеләнгән башка җиһазларны (Починок-Шемордан авылында энергия саклаучы лампаларны, светодиодлы яктырткычларны, махсус җиһазларны сатып алу, урнаштыру, ремонтлау һәм тоту)ремонтлау;

- җир асты суларының табигый чыгу урыннарын төзекләндерү (чишмәләр) (төзекләндерү, чишмәләрне тоту, проект-смета документациясе, технадзорны гамәлгә ашыру, материал сатып алу, ташу һәм чишмәләрне төзекләндерү һәм тоту буенча башка эш төрләре);

- янгын куркынычсызлыгының беренчел чараларын тәэмин итү (янгын гидрантларын, комплектлаучы детальләрне сатып алу һәм урнаштыру, комплектлаучы детальләрнең проект-смета документациясен эшләү, килешү буенча түләү);

- су белән тәэмин итү һәм ташландык суларны агызу системаларын, су күтәрү манараларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортлауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итүче башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау (Починок-Шемордан авылының Совет урамы буенча су белән

тәэмин итү трассасын ремонтлау, су күтәрү манарасы өчен насос сатып алу), проект-смета документациясен эшләү, килешү буенча түләү);

- ремонтлау, коймалар төзү, традицион Күмү урыннарын төзекләндерү (Починок-Шемордан авылындагы зиратларны саклау, материаллар, кораллар сатып алу һәм коймаларны урнаштыру, проект-смета документациясен эшләү һәм технадзорны гамәлгә ашыру, килешү буенча түләү);

- торак пункт территориясен төзекләндерү (төзелеш, инвентарь сатып алу, халыкның күпләп ял итү урыннарын ремонтлау һәм аларга якын территорияне төзекләндерү, проект-смета документациясен эшләү, килешү буенча түләү))?

«РИЗА» «КАРШЫ»

5. Җыенны оештыручы итеп Ядегәр авылы башкарма комитетын билгеләргә.

6.Әлеге карарны кабул ителгән көннән соң 5 көн эчендә мәгълүмат стендларында һәм Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында «Авыл җирлекләре» бүлегендә урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә.

7. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Ядегәр авыл җирлеге башлыгы: А.Н.Фәйзуллин